| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Менделеевский муниципальный район<br>Глава Брюшлинского сельского поселения | Татарстан Республикасы<br>Менделевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге башлыгы |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.11. 2023 ел №2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2023 елның 30 ноябрендә 17.00сәг. үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге гражданнарының җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан, карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, 18 яшькә кадәрге балалары булган ялгыз аналардан, теркәлгән, ләкин теркәлү урыны буенча 3 елдан артык яшәмәгән затлардан тыш, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1) Бөрешле авылында юлларга вак таш җәю.
2) Су алу өчен электр насослы скважина агрегаты сатып алу;
3) янгын сүндерү машинасына янгын сүндерү җиңен сатып алу;
4) Бөрешле авылындагы юлларны кардан чистарту;
5) Бөрешле авылындагы территорияне чабу

«Риза» «Каршы».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А.Смирнова